ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.01.2026 Баулы шәһәре № 6

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының 2026-2031 елларга озак вакытлы чорга бюджет фаразын раслау турында

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының «Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмә раслану турында» 2025 елның 9 сентябрендәге 322 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясенең Бюджет кодексының 170.1 статьясына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының 2026-2031 елларга озак вакытлы чорга бюджет фаразын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының бюджет һәм финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Җитәкче Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 26 гыйнварындагы
6 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының 2026-2031 елларга озак вакытлы чорга бюджет фаразы

Баулы муниципаль районының 2026-2031 елларга бюджет фаразын эшләү (алга

таба – Бюджет фаразы) Баулы муниципаль районының башкарма комитеты тарафыннан 2022 елның 12 апрелендә кабул ителгән 72 номерлы карары белән расланган озак вакытлы чорга бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибенә туры китереп үткәрелде.

Бюджет фаразы Баулы муниципаль районының 6 елга төп юнәлешләрен, бурыч, салым һәм бюджет сәясәтен, консолидацияләнгән бюджетның төп параметрларын билгели.

Бюджет фаразын формалаштыруга керемнәр алдагы елларда районның бюджет сәясәтен гамәлгә ашыру нәтиҗәләренә нигезләнә.

Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджетын башкаруның төп нәтиҗәләре

2025 елда Баулы муниципаль районы бюджетының керем өлеше физик затлар керемнәренә салым күләменең «Алойл» ЯАҖнең кече нефть компаниясеннән дивидендлардан кергән өлешен исәпкә алмыйча, узган ел дәрәҗәсенә караганда 108,5 процентка арткан. Салым һәм салым булмаган керемнәр Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджетына 817 млн. 929 мең сум күләмендә кергән, бу физик затлар керемнәренә салымны исәпкә алмыйча, 2024 елга караганда, 57 млн. 773 мең сумга күбрәк.

2025 елда Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджеты чыгымнарын финанслау заем чыганакларын кулланмыйча тәэмин ителде. Социаль йөкләмәләр тулысынча үтәлде.

Озак вакытлы чорга салым, бюджет һәм бурыч сәясәте формалаштыруга төп алымнар

Баулы муниципаль районының озак вакытлы чорда салым, бюджет һәм бурыч сәясәтен гамәлгә ашыруның төп максатлары булып бюджет системасының тотрыклылыгын һәм баланслыгын саклау, халыкның яшәү сыйфатын күтәрү тора.

Салым сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында фаразлана торган чорда Баулы муниципаль районының берләштерелгән бюджеты керемнәре, икътисад секторларына салым салуның төп параметрларын саклап калуны исәпкә алып, 2031 елга кадәрге чорга Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең төп күрсәткечләрен бәяләүдән чыгып билгеләнә. Салым һәм салым булмаган керемнәрне фаразлаганда алдагы елларда барлыкка килгән тенденцияләр исәпкә алынган. Гомумән алганда, бюджет керемнәрен формалаштыру сәясәте салым һәм салым булмаган керемнәр буенча законнарны камилләштерү механизмнарын кулланып, ташламаларның нәтиҗәлелеген

бәяләү, дәүләт һәм муниципаль милекне куллану нәтиҗәлелеген күтәрү системалы якын килүгә нигезләнә.

2031 елга кадәр Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджетының төп керем чыганаклары сакланачак. Бу физик затлар кеременә салым, җир салымы, гомуми керемгә салымнар.

Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджетын тигезләү максатыннан, бюджетка керемнәрне мобилизацияләү буенча киңәйтелгән чаралар комплексы алга таба да тормышка ашырылачак.

Керемнәр үсеше эшлекле климатны яхшырту, сәнәгать җитештерүен үстерү, эшмәкәрлеккә һәм кече бизнеска ярдәм итү, керемнәрне администрацияләүнең нәтиҗәлелеген арттыру исәбенә тәэмин ителәчәк.

Киләсе чорда иң мөһим бурычларның берсе бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру булырга тиеш. Аерым алганда, муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм финанслау формаларын үстерү һәм камилләштерү, нәтиҗәсез муниципаль учреждениеләрне ачыклау белән бюджет секторын эзлекле оптимизацияләүне дәвам итү, социаль-мәдәни өлкә учреждениеләренең эшчәнлеген һәм күрсәтелгән хезмәтләр сыйфатын даими мониторинглау, норматив финанслау инструментларын камилләштерү, муниципаль учреждениеләрнең түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керем алу мәсьәләләренә игътибарны арттыру кирәк.

Барлык дәрәҗә бюджетларының тигезлеген һәм тотрыклылыгын тәэмин иткәндә мөһим фактор булып реаль финанс чыганаклары белән тәэмин ителмәгән бюджет йөкләмәләрен кабул итүдән баш тарту принцибын һичшиксез үтәү калачак.

Авыл җирлекләре бюджетлары белән бюджетара мөнәсәбәтләре өлкәсендә төп бурыч булып чыгым вәкаләтләрен керем чыганаклары белән тулысынча тәэмин итеп, максималь тигезлек шартларын булдыру калачак.

Баулы муниципаль районының икътисади үсеш сценарийлары тасвирламасы

Баулы муниципаль районының 2031 елга кадәрге социаль-икътисадый үсеш фаразы Баулы муниципаль район Советының 2025 елның 12 декабрендәге 19 номерлы карары белән расланган 2027-2028 елларга район үсеше фаразы параметрларын, шулай ук 2015-2030 елларга Баулы районының төп социаль-икътисадый күрсәткечләрен исәпкә алып, база варианты нигезендә эшләнде.

Демографик күрсәткечләр

2025 елның 1 гыйнварына Баулы муниципаль районының уртача еллык халык саны 31 940 кеше тәшкил итә, бу алдагы ел дәрәҗәсенә 99,13% туры килә. 2024 елда халыкның табигый кимүе 308 кеше тәшкил итте, миграция артуы 10 кеше булды. Алга таба миграция процесслары һәм демографик сәясәт нәтиҗәсендә район халкы санының ел саен кимүе фаразлана. Районда демографик хәл халыкның табигый киму процессы белән характерлана, бу югары үлем дәрәҗәсе һәм түбән туу дәрәҗәсе, шулай ук эшкә яраклы халыкның зур шәһәрләргә китүе белән бәйле, 2031 елга район халкы саны 30 мең кеше тәшкил итәчәк.

Икътисади күрсәткечләр

2024 елда тулаем территориаль продукт 67,3 млрд. сум тәшкил итте, алдагы ел белән чагыштырганда үсеш темпы чагыштырма бәяләрдә – 100,4% булды. 2025 елда тулаем территориаль продукт күләме 69,3 млрд. сум дип бәяләнә, алдагы ел белән чагыштырганда үсеш темпы – 95,8%. ВТП структурасында нефть тармагы өлеше 74,7% тәшкил итә, шуңа бәйле рәвештә тулай территориаль продуктның үсеш темпы нефть чыгару бәяләренә һәм күләменә бәйле. Фаразланган мәгълүматларны исәпкә алып, чагыштырма бәяләрдә үсеш темпы план чорында-2026 елда - 98,4%, 2027 елда - 99,6%, 2028 елда - 100,0%, 2029-2030 елларда – 102,6%, 2031 елда – 102,8% дәрәҗәсендә көтелә.

2025 елда үз җитештерү товарлары, башкарылган эшләр һәм хезмәтләр күләме (гамәлдәге бәяләрдә) 16,3 млрд. сум дип бәяләнә. 2026 елда предприятиеләр эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча күләмнәрнең 2025 ел дәрәҗәсенә карата 17,6% артуы һәм 19,3 млрд. сум тәшкил итүе көтелә, 2027 елда прогноз буенча 20,2 млрд. сум, 2028 елда – 21,2 млрд. сум, 2030 елда – 23,7 млрд. сум, 2031 елда – 25,1 млрд. сум тәшкил итәчәк. 2026 елда сәнәгать җитештерү индексы 100,2% дәрәҗәсендә көтелә.

2025 елда кече һәм урта предприятиеләрнең (микропредприятиеләрне дә кертеп) әйләнеш үсеш темпы 2024 ел дәрәҗәсенә карата 5,6% яки 4,3 млрд. сум тәшкил итәчәк. Алдагы елларда да үсешнең уңай динамикасы 7%ка кадәр булыр дип фаразлана, 2031 елга кече предприятиеләрнең әйләнеше фараз буенча 6 млрд. сумнан артып китәчәк.

2025 елда авыл хуҗалыгы продукциясе барлык хуҗалык категорияләрендә 4,1 млрд. сум тәшкил итәчәк дип бәяләнә, 2026 елда уңай һава шартларында 4,5 млрд. сум тәшкил итәчәк, бу алдагы елга чагыштырмача 104,9% булачак. Алдагы фаразланган чорларда

үсеш 106-107% белән планлаштырыла. 2031 елга бу күрсәткеч фараз буенча 7,915 млрд. сум тәшкил итәчәк.

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең бурычы – савым сыерларның баш санын саклау һәм арттыру, туфракның уңдырышлылыгын күтәрү, моның өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм район җитәкчелеге тарафыннан эшләнгән дәүләт ярдәме программалары бар, әлеге дәүләт ярдәме чаралары Баулы районы фермерлары тарафыннан актив кулланыла.

2024 елда барлык финанслау чыганаклары хисабына төп капиталга инвестицияләр күләме 11 млрд. 154 млн. сум тәшкил итте, 2025 елда инвестицияләр күләме бәяләмә буенча 9 млрд. 593 млн. сум тәшкил итәчәк, 2031 елга фараз буенча 13,1 млрд. сум тәшкил итәчәк. Проектлар матди-техник базаны яңартуга, техника һәм предприятиеләрнең җитештерүен модернизацияләүгә юнәлдерелгән.

2024 елда ваклап сату әйләнеше 7 млрд сум тәшкил итте, чагыштырыла торган бәяләрдә үсеш темпы 110,7% булды. 2025 елда бәя буенча 7 млрд 622 млн сум тәшкил итәчәк, үсеш 0,5% булачак. 2026 елда ваклап сату әйләнеше якынча 8 млрд сум тәшкил итәчәк, 2031 елга фараз буенча 12,9 млрд сум дәрәҗәсендә булачак, еллык үсеш темпы 4% тан 5% ка кадәр.

## Хезмәт һәм эш белән тәэмин ителеш күрсәткечләре

2026-2031 елларда икътисадта эшләүчеләр саны 16,5-16,7 мең кеше дәрәҗәсендә фаразлана.

2025 елда район буенча бер хезмәткәргә исәпләнгән уртача айлык хезмәт хакы бәяләмә буенча 78 мең 315 сум тәшкил итте, үсеш темпы 2024 ел дәрәҗәсенә карата 116,3% булды. 2026 елда фараз буенча район буенча хезмәт хакы күләме 87 мең 690 сум тәшкил итәчәк, үсеш темпы 111,97%, 2031 елга 147 мең 114 сум тәшкил итәчәк, үсеш темпы 109-112%.

2024 елда җан башына акчалата керемнәр 51 мең 241 сум тәшкил итте. 2025 елда 61 мең 54 сум тәшкил итәчәк, 2024 ел дәрәҗәсенә үсеш темпы 119,15% булачак. Фараз буенча, 2031 елга җан башына акчалата керемнәр 116 мең 841 сум тәшкил итәчәк.

2024 елда теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе 0,16% тәшкил итте, теркәлгән эшсезләр саны 30 кеше булды. 2031 елга кадәр бу күрсәткеч 0,13%ка кадәр кимүе фаразлана.

Кадрлар җитешмәгән шартларда икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итүнең төп факторы булып хезмәт җитештерүчәнлеген һәм хезмәт ресурсларын нәтиҗәле

файдалануны арттыру тора.

Фаразлаулы күрсәткечләрне үтәүдә предприятиеләрнең өзлексез эшләвен тәэмин итү һәм инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны исәпкә алып аларны алга таба үстерү, сату базарларын киңәйтү, технологик үсеш һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, ахыр чиктә предприятиеләрнең һәм оешмаларның финанс нәтиҗәләре һәм бюджет керемнәре бәйле булачак.

## Баулы муниципаль районының озак вакытлы чорга бюджет фаразын формалаштыру шартлары, бюджетның төп характеристикалары фаразы

Баулы муниципаль районының 2028 - 2031 елларга керемнәр һәм чыгымнар буенча бюджет фаразы Баулы муниципаль районының 2031 елга кадәр социаль-икътисади үсешенең озак сроклы фаразы нигезендә төп вариантта төзелде.

## Баулы муниципаль районы бюджеты керемнәре

Баулы муниципаль районы бюджеты керемнәрен фаразлаганда Россия Федерациясе законнарындагы үзгәрешләр исәпкә алынды.

Баулы муниципаль районы бюджетының төп салым керемнәре буенча керемнәр фаразы, 2031 елга кадәр Баулы муниципаль районының социаль-икътисади үсеш фаразында салынган икътисади күрсәткечләр динамикасыннан чыгып төзелгән.

## Баулы муниципаль районы бюджеты чыгымнары

Баулы муниципаль районы бюджеты чыгымнарын исәпләү Бюджет фаразын эшләү кысаларында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы гамәлдәге законнары шартларында, шул исәптән Баулы муниципаль районы муниципаль программалары буенча инфляция күләменә индексацияне исәпкә алып башкарылды.

## Бюджет фаразын гамәлгә ашыру барышында барлыкка килгән төп куркынычлар һәм аларны профилактикалау механизмнары

Бюджет куркынычларын минимальләштерүгә гомуми якын килү Баулы муниципаль районының гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен кабул ителгән карарларны тормышка ашыру чыгымнарын киметмичә тәэмин итү мөмкинлегеннән гыйбарәт. Шуны исәпкә алып, бюджет балансын тәэмин итү максатында, Баулы муниципаль районы бюджеты һәм җирле

бюджетлар керемнәре кимегән очракта, иң беренче чиратта шартлы рәвештә расланган чыгымнар кыскартылачак.

Икътисади тотрыксызлык шартларында Баулы муниципаль районы бюджет системасы өчен иң тискәре нәтиҗәләр һәм куркынычлар булып түбәндәгеләр тора:

Баулы муниципаль районының социаль-икътисади үсеш фаразланган параметрларына ирешмәү;

Баулы муниципаль районы бюджетына түләүләр һәм бюджеттан тыш эшчәнлектән керемнәр киму.

Бюджет куркынычларын минимальләштерү чаралары:

керем потенциалын арттыру;

социаль әһәмиятле чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен бюджетларның керем өлешен үтәү.

Озак вакытлы чорда Баулы муниципаль районының муниципаль финанслар белән идарә итүнең сыйфатын күтәрү һәм бюджет акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү буенча эшне дәвам итәргә кирәк.

2031 елга кадәр Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең озак вакытлы фаразының төп күрсәткечләре

| Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2031 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хисап | Бәя | Фараз | Фараз | Фараз | Фараз | Фараз | Фараз |
| Төп күрсәткечләр | | | | | | | | | |
| Халык саны (уртача еллык) | мең кеше | 31,09 | 31,81 | 31,50 | 31,20 | 31,00 | 30,90 | 30,80 | 30,70 |
| узган елга карата | % | 98,80 | 99,13 | 99,03 | 99,05 | 99,36 | 99,68 | 99,68 | 99,68 |
| Тулаем төбәк продукты | млн сум | 67 312,0 | 69 351,02 | 73 052,02 | 76 766,11 | 80 646,18 | 85 323,65 | 90 528,39 | 96 231,68 |
| чагыштырыла торган бәяләрдә узган елга карата | % | 100,4 | 95,8 | 98,4 | 99,6 | 100,0 | 102,5 | 102,6 | 102,8 |
| Элеккеге ел белән чагыштырганда дефлятор индексы | % | 109,3 | 107,6 | 107,1 | 105,5 | 105,1 | 103,2 | 103,4 | 103,4 |
| Үзләре җитештергән төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр күләме | мең сумнарда | 18 310 714,0 | 16 354 732,96 | 19 255 840,22 | 20 204 344,39 | 21 221 350,27 | 22 494 631,29 | 23 686 846,75 | 25 036 997,01 |
| Сәнәгать җитештерүе индексы узган елга карата | % | 99,8 | 99,6 | 100,2 | 100,6 | 100,8 | 100,4 | 100,6 | 100,8 |
| Микропредприятиеләрне дә кертеп, кече һәм урта предприятиеләр әйләнеше | мең сумнарда | 4 027 128,8 | 4 252 648,01 | 4 537 575,42 | 4 900 581,45 | 5 243 622,15 | 5 589 701,21 | 5 930 672,98 | 6 304 305,38 |
| узган елга карата | % | 109,4 | 105,6 | 106,7 | 108,0 | 107,0 | 106,6 | 106,1 | 106,3 |
| Авыл хуҗалыгы продукциясе барлык категория хуҗалыкларында | мең сумнарда | 3 672 000,0 | 4 112 900,2 | 4 523 900,2 | 5 021 500,0 | 5 624 100,0 | 6 276 495,6 | 7 042 228,06 | 7 915 454,34 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| узган елга карата чагыштырыла торган бәяләрдә | % | 112,4 | 104,1 | 104,9 | 106,2 | 107,5 | 106,7 | 107,2 | 107,1 |
| узган елга карата дефлятор индексы | % | 108,3 | 107,6 | 104,9 | 104,5 | 104,2 | 104,6 | 104,7 | 104,9 |
| Финанслауның барлык чыганаклары исәбеннән төп капиталга инвестицияләр күләме | мең сумнарда | 11 154 501,0 | 9 592 870,9 | 10 014 957,2 | 10 675 944,4 | 11 337 852,9 | 11 882 069,84 | 12 488 055,4 | 13 149 922,34 |
| чагыштырыла торган бәяләрдә узган елга карата | % | 145,3 | 79,8 | 99,1 | 102,1 | 101,8 | 100,8 | 101,1 | 101,3 |
| узган елга карата дефлятор индексы | % | 108,1 | 107,8 | 105,3 | 104,4 | 104,3 | 104,0 | 104,0 | 104,0 |
| "Төзелеш" эшчәнлеге төре буенча башкарылган эшләр күләме | мең сумнарда | 171 080,0 | 309 042,59 | 334 075,03 | 356 123,98 | 382 469,00 | 413 075,32 | 445 295,19 | 480 918,81 |
| узган елга карата чагыштырыла торган бәяләрдә | % | 208,49 | 171,55 | 103,35 | 102,01 | 102,97 | 103,65 | 103,36 | 103,55 |
| узган елга карата дефлятор индексы | % | 107,8 | 105,3 | 104,6 | 104,5 | 104,3 | 104,2 | 104,3 | 104,30 |
| Ваклап сату әйләнеше | мең сумнарда | 6 986 718,0 | 7 622 509,3 | 8 371 802,0 | 9 168 127,8 | 10 011 5985,6 | 10 892 616,01 | 11 829 380,99 | 12 870 366,52 |
| узган елга карата чагыштырыла торган бәяләрдә | % | 110,7 | 100,5 | 104,6 | 105,3 | 105,0 | 104,7 | 104,6 | 104,8 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| узган елга карата дефлятор индексы | % | 107,7 | 108,6 | 105,0 | 104,0 | 104,0 | 103,9 | 103,8 | 103,8 |
| Уртача айлык номиналь исәпләнгән хезмәт хакы | сумнарда | 67 341,8 | 78 315,42 | 87 690,32 | 95 713,74 | 104 439,89 | 116 032,72 | 130 304,74 | 147 114,05 |
| узган елга карата | % | 119,31 | 116,3 | 111,97 | 109,15 | 109,12 | 111,10 | 112,30 | 112,90 |
| Бер кешегә акчалата керемнәр (уртача айга) | сумнарда | 51 241,70 | 61 054,43 | 69 518,00 | 77 428,08 | 85 588,18 | 94 660,53 | 105 073,19 | 116 841,39 |
| узган елга карата | % | 121,67 | 119,15 | 113,86 | 111,38 | 110,54 | 110,60 | 111,00 | 111,20 |
| Теркәлгән эшсезләр саны (чор ахырына) | кеше | 30,0 | 28,0 | 28,0 | 28,0 | 28,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 |
| Теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе (чор ахырына) | % | 0,16 | 0,15 | 0,15 | 0,15 | 0,15 | 0,13 | 0,13 | 0,13 |

Баулы муниципаль районы берләштерелгән бюджетының һәм Баулы муниципаль районы бюджетының төп характеристикалары фаразы

(мең сумнарда)

| Төп характеристикаларның атамасы | 2026 ел | | 2027 ел | | 2028 ел | | 2029 ел | | 2030 ел | | 2031 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджеты | Баулы муниципаль районы бюджеты | Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджеты | Баулы муниципаль районы бюджеты | Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджеты | Баулы муниципаль районы бюджеты | Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджеты | Баулы муниципаль районы бюджеты | Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджеты | Баулы муниципаль районы бюджеты | Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджеты | Баулы муниципаль районы бюджеты |
| 1 | 2 | | 3 | | 4 | | 5 | | 6 | | 7 | |
| Керемнәр, шул исәптән: | 1964125,03 | 1919146,23 | 2111261,94 | 2063607,74 | 2275030,37 | 2232472,97 | 2275030,37 | 2232472,97 | 2275030,37 | 2232472,97 | 2275030,37 | 2232472,97 |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| салым һәм салым булмаган | 781497,1 | 609510,1 | 790478,0 | 609760,5 | 809629,0 | 619606,5 | 809629,0 | 619606,5 | 809629,0 | 619606,5 | 809629,0 | 619606,5 |
| бушка күчерүләр | 1182627,93 | 1309636,13 | 1320783,94 | 1453847,24 | 1465401,37 | 1612866,47 | 1465401,37 | 1612866,47 | 1465401,37 | 1612866,47 | 1465401,37 | 1612866,47 |
| Чыгымнар, шул исәптән: | 1964125,03 | 1919146,23 | 2111261,94 | 2063607,74 | 2275030,37 | 2232472,97 | 2275030,37 | 2232472,97 | 2275030,37 | 2232472,97 | 2275030,37 | 2232472,97 |
| Баулы муниципаль районы программаларының финанс тәэминаты | 1656013,4 | 1654831,9 | 1777670,3 | 1776488,8 | 1905545,6 | 1904364,1 | 1905545,6 | 1904364,1 | 1905545,6 | 1904364,1 | 1905545,6 | 1904364,1 |
| Дефицит | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |